| | |
|---|---|
| **Совет Нурлатского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл жирлеге Советы** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 февраль 2019 ел** **№174**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодол муниципаль районы Норлат авыл жирлеге муниципаль берәмлегендә вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләрен раслау турында»гы Зеленодольск муниципаль районы «районы Норла авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 150нче карарына үзгәрешләр кертү турында.

Зеленодольск муниципаль районы Норла авыл жирлеге башлыгы Р.Р. Багаутдинов мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы (№25-ФЗ 02.03.2007 ел) Федераль законга яраклы рәвештә, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә, Зеленодольск муниципаль район Норла авыл жирлеге Советы түбәндәге карар итте:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норла авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибе турындагы, Зеленодольск муниципаль районы Норла авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган 2018 елның 14 сентяберендә 150нче «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вакантлы вазифаларны алмаштыру буенча конкурс уздыру тәртибенең Кагыйдәләрен раслау турында»гы Кагыйдәгә (алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Кагыйдәнең 4нче пункының 5нче өлешендә «һәм зурлар» сүзләрен «,зурлар һәм алып баручылар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2)10нчы пунктны яңа редакциядә язарга:

«10. Бәйгедә катнашырга теләүчеләр, конкурс комиссиясенә түбәндәге документлар беркетелгән гариза тапшыралар:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең боерыгы (№667-р, 26.05.2005 ел) белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

2) паспорт;

3) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагы булмаганда, хезмәт кенәгәсе;

4) 1елеем турында документ;

5) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелү очрагы булмаганда, пенсияне мәҗбүри иминиятләштерү таныклыгы;

6) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органына учетка кую турында таныклык;

7) запастагы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен

– хәрби учет документы;

8) муниципаль хезмәткә керешүгә киртә булмаслык авыруларның юклыгы турында медицина оешмасы биргән белешмә;

9) «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр һәм Россия Федерациясе Президенты актларының кайберләренә үзгәрешләр кертү турындагы белешмә формаларын раслау турында»гы (23.06.2014 ел, №460) Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган форма буенча тутырылган конкурс уздырылган елдан алдагы календарь ел өчен керемнәр турында, гражданинның милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре һәм шулай ук, хатынының (иренең) конкурс уздырылган елдан алдагы календарь ел өчен керемнәр, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре, гражданинның балигъ булмаган балалары турында мәгълүмат;

10) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» (02.03.2007 ел, №25-ФЗ) Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган мәгълүмат;

11)Федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күрсәтелгән башка документлар;

1.3. Зеленодольск муниципаль районы Норла авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 150 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының " Норлат авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә)

2.Шушы карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталы составындагы Зеленодол муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.

5. 3. Әлеге карарның үтәлеше буенча контрольне Зеленодол муниципаль районы Норлат авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

**Норлат авыл жирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Р.Р.Багаутдинов**